СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 3-2 от «14» ноября 2025 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурсны кабат үткәрү турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә муниципаль район Советының 2025 елның 22 сентябрендәге № 6-1 карары белән игълан ителгән конкурсны уздырылмаган дип тану сәбәпле, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясының 3 нче өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясы, Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 46 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурсны кабат уздыру турында игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылардан конкурска документлар «Нократ» («Вятка») газетасында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турында хәбәр рәсми басылып чыккан көннән алып 20 көн эчендә кабул итәргә. Документлар түбәндәге адрес буенча тапшырыла: Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Мамадыш шәһәре, Совет урамы, 2 В йорт, 3 нче кабинет, көн саен 8.00 дән 12.00 гә кадәр һәм 13.00 дән 17.00 гә кадәр, ял һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәреннән тыш, телефон - 8 (85563) 3-12-67.

3. Конкурсны 2025 нче елның 12 декабрендә 10.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Мамадыш шәһәре, Совет урамы.

4. Конкурсны Татарстан Республикасы Рәисенең 2025 елның 4 сентябрендәге 708 номерлы Указы белән расланган составтагы комиссия һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2025

000111

елнын 22 сентябрендәге 6-1 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмә нигезендә уздырырга.

5. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турында «Нократ» («Вятка») газетасында хәбәр урнаштырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы аппараты Җитәкчесенә йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Башлыгы В.И.Никитин